**СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422619 с. Малая Елга,
ул. Советская, д.58
тел: 8-84378 3-25-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422619 Кече Елга авылы,
Совет урамы, 58 нчы йорт,
тел: 8-84378 3-25-16

---

**2020елның «29» октябре** **7 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башлыгының, Кече Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләүләре күләмен арттыру турында**

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» ТР МКның 2020 елның 6 августындагы 658-р номерлы карары нигезендә, Кече Елга авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Кече Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 5 номерлы «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " карары белән расланган муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга».
2. Кече Елга авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 11 апрелендәге 5 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтнең алар билгән вазыйфалары нигезендә Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга»
3. Кече Елга авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең

вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Лаеш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Кече Елга авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.А.Кыямова**